**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИАЛЬ РАЙОНЫ
КҮЛЛЕ-КИМЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422742, Күлле-Киме авылы, Киров урамы,1А йорты
Тел.: (8-84369) 3-53-97; факс: 3-53-40

**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КУЛЛЕ-КИМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АТНИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

422742, село Кулле-Кими, ул. Кирова, д.1А
Тел.: (8-84369) 3-53-97; факс: 3-53-40

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«29» июль 2025 ел. № 8

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл башкарма комитеты җитәкчесенең 2017 елның 28 февралендәге 5 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар план-графигын формалаштыру, раслау һәм алып бару тәртибенә” үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

"Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында" 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әтнә районы прокуратурасының 2025 елның 16 июнендәге 02-08-02-2025 номерлы протесты нигезендә, Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авылы башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл башкарма комитеты җитәкчесенең 2017 елның 28 февралендәге 5 номерлы карары (21.07.2021 №17, 03.04.2023 №6, 30.09.2024, № 9 редакциясендә) белән расланган “Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар план-графигын формалаштыру, раслау һәм алып бару тәртибенә” түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

**1.1. Тәртипнең 8 пунктындагы "а"** пунктчасында "1-4 пунктлары" сүзләрен "1-5 пунктлары" сүзләренә алмаштырырга;

**1.2. Тәртипнең 9 пунктын** түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:

«9. План-графикка үзгәрешләр кертү тиешле сатып алу турында белдерүне бердәм мәгълүмат системасында урнаштыру көненә кадәр яки тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) ябык ысул белән билгеләүдә катнашырга чакыру җибәрү көненә кадәр бер көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырылырга мөмкин, яисә Законның 93 статьясының 1 өлеше нигезендә бердәнбер тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) белән контракт төзегән очракта – контракт төзелгән көнгә кадәр бер көннән дә соңга калмыйча».

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (http://atnya.tatarstan.ru/ ) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru ) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Күлле-Киме авыл башкарма комитеты
җитәкчесе: Гәрәев Х.Х.